**СОВЕТ**
**Исенбаевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Исәнбай авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.10.2019 Исәнбай авылы номер 51-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының 31.01.2019 48-1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексы, муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 ел, № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, “Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” Федераль закон һәм “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 01.04.2009 ел, № 48-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының 31.01.2019 48-1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**а) 15 бүлекнең 15.14 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:**

«15.14. Әлеге бүлекнең 15.13 пункты нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы "Аерым категория затларның Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю" Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия

Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка бүтән җаваплылык чараларын куллану турвында гариза белән мөрәҗәгать итә».

**б) 16 бүлекнең 16.3. өлешендәге 6нчы пунктны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:**

"6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслаучы документ;».

**в) 27нче бүлекнең 27.9. пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:**

"27.9. Дисциплинар җәза хезмәткәрнең авыру вакытын, отпускта булу вакытын, шулай ук хезмәткәрләрнең вәкиллекле органы фикерен исәпкә алу өчен кирәкле вакытны исәпкә алмыйча, җинаять ачыкланган көннән бер айдан да соңга калмыйча кулланыла.

Дисциплинар җәза, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәзадан тыш, җинаять кылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, ревизия, финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү яки аудиторлык тикшерүе нәтиҗәләре буенча (кылган көннән ике елдан соң) кулланыла алмый. Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән, бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәза җинаять кылган көннән соң өч елдан да соңга калмыйча кулланыла алмый. Күрсәтелгән срокларда җинаять эше буенча призводство вакыты кертелми».

**г) 29нчы бүлекнең 29.6 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:**

«29.6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча тиешле елларны эшләгән өчен пенсиянең максималь күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча хезмәт окладының максималь күләме кулланыла (вазыйфаи оклад максималь һәм минималь әһәмияткә ия булса), ә класс чины өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгеләүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив хокукый акты белән билгеләнгән мәгънәдә исәпкә алына.».

2. Әлеге карарны Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе Ф.Ф.Сираев